ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 27 » декабрь 2021 ел № 2274

**Арча муниципаль районында хезмәтне саклау олкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында**

Арча муниципаль районында хезмәтне саклау һәм аны яхшырту өлкәсендә гражданнарның социаль-хезмәти хокукларын гамәлгә ашыру, аны яхшырту эшләрен камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау олкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 10 октябрендәге 799 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләре нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Хезмәтне саклау буенча район координация советы турында нигезләмәне (1 нче кушымта) кушымта нигезендә кабул итәргә.

2.Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча район координация советы составын расларга (2 нче кушымта).

3. Төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә, җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- хезмәтне саклау олкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә, җитештерүдә имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтү чаралары күрергә;

- хезмәтне саклау буенча комитетлар (комиссияләр) төзергә;

- хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау программаларын эшләргә һәм расларга;

- хезмәтне саклау буенча семинарлар, киңәшмәләр, хезмәтне саклау көннәре үткәрергә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «Арча муниципаль районында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 1142 номерлы карарын (16.02.2016 №151а, 15.11.2018 №1140, 17.02.2020 № 101, 28.10.2020 № 846, 06.04.2021 №240 үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"27" 12 2021 ел,*
*№274 карарына 1 нче кушымта*

**Хезмәтне саклау буенча район координация советы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

Әлеге нигезләмә җирле үзидарә органнарына үз территорияләрендә хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту эшен оештыруда, производствода имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтүдә ярдәм күрсәтү өчен эшләнде.

Нигезләмә «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нигезендә эшләнде.

Әлеге нигезләмә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Хезмәтне саклау буенча координация советының (алга таба - Координация советы) төп бурычларын, функцияләрен һәм хокукларын күздә тота.

1. **Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Координация советы җирле үзидарә органнарының эш бирүчеләр, предприятиеләрнең хезмәтне саклау хезмәтләре, хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт идарәсе, күзәтчелек һәм контроль органнары, һөнәри берлекләр һәм башка иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итүен тормышка ашыра.

1.2. Координация советы иҗтимагый орган булып тора.

1.3. Координация советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы карарларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук район башлыгы, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарларына һәм күрсәтмәләренә таяна.

1.4. Координация советы составына районның җирле үзидарә органнары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, прокуратура, эчке эшләр органнары, Роспотребнадзор вәкилләре, төрле милек рәвешләрендәге һәм эшчәнлек төрләрендәге предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләре, һөнәр берлекләре һәм башка иҗтимагый оешмалар вәкилләре керә ала.

1.5. Координация советы рәисе булып район башкарма комитеты җитәкчесе яки аның урынбасарларының берсе торырга мөмкин.

1.6. Координация советы үз эшчәнлегең эш планы нигезендә гамәлгә ашыра, ул Координация советы утырышында кабул ителә һәм Координация советы рәисе тарафыннан раслана.

1.7. Координация советы утырышларын кварталга кимендә 1 тапкыр үткәрергә киңәш ителә.

1.8. Координация советы карарлары (тәкъдимнәре) ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен Координация советы утырышында катнашкан әгъзаларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, Координация советы рәисе тавышы хәлиткеч була.

1.9. Координация советы утырышы рәис һәм секретарь имзасы куелган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 2. Координация советы бурычлары

Координация советына түбәндәге бурычлар йөкләнә:

2.1. Район территориясендә хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау, җитештерүдә имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны киметү эшчәнлеген координацияләү.

2.2. Район предприятиеләрендә хезмәт шартларының һәм хезмәтне саклауның торышын анализлау һәм тиешле тәкъдимнәр әзерләү.

2.3. Хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программага кертү өчен оештыру-техник, санитар-савыктыру һәм башка чаралар эшләү буенча тәкъдимнәрне карау.

2.4. Район предприятиеләрендә хезмәткәрләрнең имин һәм сәламәт хезмәт шартларына хокукларын яклауны тәэмин итү.

## 2. Координация советы функцияләре

Куелган бурычларны үтәү өчен Координация советына түбәндәге функцияләрне йөкләү тәкъдим ителә:

3.1. Район территориясендә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча гамәлдәге законнарны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне карау.

3.2. Районның хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча территориаль программалар эшләү өчен эшче төркемнәр оештыру.

3.3. Хезмәтне саклау һәм җитештерү санитариясе өлкәсендә профилактика эшенең алдынгы ысулларын һәм формаларын гамәлгә кертүдә предприятиеләргә ярдәм итү.

3.4. Координация советы утырышында каралганнан соң, производствода имгәнүләр, һәлакәтләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе югары булган предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең хезмәт шартларын һәм аларны саклау торышын комплекслы тикшерү.

3.5. Хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау, ял итүчеләрнең иминлеген тикшерү максатыннан, җәйге сезон ачылыр алдыннан

балаларны савыктыру, студентлар лагерьларын, ял базаларын комплекслы тикшерү.

3.6. Район предприятиеләрендә булган барлык төркемдәге бәхетсезлек очракларын һәм үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары нәтиҗәләрен тикшерү.

3.7. Предприятие җитәкчеләренең имгәнүләрне һәм һөнәри авыруларны кисәтү буенча профилактик чаралар турындагы хисапларын тыңлау.

3.8. Коллектив шартнамәләр һәм хезмәтне саклау буенча килешүләр төзү, хезмәт шартлары һәм имгәнү куркынычсызлыгы буенча эш урыннарын аттестацияләү, хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча җитәкчеләрне һәм белгечләрне укыту, махсус кием, аяк киеме һәм башка шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эш торышын тикшерү.

3.9. Район предприятиеләрендә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау буенча смотр-конкурслар уздыру мәсьәләләре турында фикер алышу.

3.10. Дәүләт шәһәр техник күзәтчелеге карамагындагы бина һәм корылмаларда, объектлар һәм производстволарда шартлау, янгын һәм электр куркынычсызлыгы, техник торышы буенча максатчан тикшерү үткәрү.

3.11. Татарстан Республикасының башка районнарының һәм Россия Федерациясе төбәкләренең хезмәт шартлары һәм аларны саклау буенча уңай эш тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату.

3.12. Предприятие җитәкчеләренә хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча конкрет чаралар күрү буенча тәкъдимнәр кертү.

### 3. Координация советы хокуклары

4.1. Милеккә бәйсез рәвештә территориядә урнашкан предприятиеләргә керә алу.

4.2. Эш бирүчеләрдән, күзәтчелек һәм контроль органнарыннан хезмәтне саклау һәм хезмәт шартлары мәсьәләләре буенча мәгълүмат соратып алу.

4.3. Эш урыннарында сәламәт һәм имин хезмәт шартлары тәэмин итү бурычларын үтәү мәсьәләләре буенча утырышларда эш бирүчеләрне тыңлау.

4.4. Предприятиеләр җитәкчеләренә хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр кертү.

4.5. Муниципаль район башлыгына, Башкарма комитет җитәкчесенә, Башкарма комитет каршындагы административ комиссиягә, прокуратурага хезмәтне саклау законнарын бозган, имгәнүләр һәм һөнәри авырулар дәрәҗәсе югары булган өчен предприятие җитәкчеләренә тиешле чаралар күрү турында тәкъдимнәр кертү.

4.6. Татарстан Республикасында хезмәт шартлары һәм хезмәтне саклау буенча закон чыгару һәм норматив базаны яхшырту һәм камилләштерү буенча хезмәтне саклау буенча дәүләт идарәсе органнарына тәкъдимнәр кертү.

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*"27" 12 2021 ел,*
*№ 2741 карарына 2 нче кушымта*

**Хезмәтне саклау буенча район координация советы**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Вафина Эльвира Шамилевна | - Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Координация советы рәисе; |
| Фазылҗанова Гүзәл Ренатовна | - Арча районының «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ әйдәп баручы инспекторы - Координация советы секретаре (килешү буенча). |
| ***Совет әгъзалары:*** | |
| Шакирова Миләүшә Ниязовна | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районында социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Нәбиуллин Илшат Миңнегалиевич | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының хезмәтне саклау буенча белгече; |
| Закиров Эдуард Айдарович | - РФ Тикшерү комитетының ТР буенча тикшерү идарәсенең Арча районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бәһавиев Айдар Рашатович | - Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Гатиятов Ренат Мансурович | - Арча муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Гафурова Эльмира Шәйхулловна | - Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе 8 нче филиалының вәкаләтле вәкиле (килешү буенча); |
| Галимова Светлана Петровна | - Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы җитәкчесе; |
| Гыйбадуллина Гөлфия Мансуровна | - Арча районының «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Юзаев Искәндәр Илнарович | - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе башлыгы (ПСО 7 ПСЧ) |

| | |
|---|---|
| | (килешү буенча); |
| Фазылов Радик Рашатович | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; |
| Харисов Вакыйф Вәгыйзович | - Арча муниципаль районы Һөнәр берлекләре оешмаларының координация советы рәисе (килешү буенча); |
| Мифтахетдинова Надия Равилевна | - Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Арча муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Салкова Эльвира Валентиновна | - Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Арча, Биектау, Әтнә, Балтач муниципаль районнарында территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча). |